**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЫЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

5 август, 2019 ел №149

**Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Кызылтау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Кызылтау авыл җирлеге Советының 2016 ел, 12 февраль 16 нче номерлы карары белән расланган “Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

15.6 пунктында "ә стажның озынлыгы һәм ай саен түләү әлеге кодекс нигезендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук мәгънәләрдә исәпкә алына" сүзләрен "ә сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгеләүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына"сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кызылтау авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Кызылтау авыл җирлеге башлыгы –**
**Кызылтау авыл җирлеге Совет Рәисе** **Ш.Р.Гаффаров**